**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**

**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы № 10 «02» сентябрь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 148 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законның 1 статьясындагы 1 пункты нигезендә

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 148 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7 пунктны түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац белән тулыландырырга:

«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә

ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган авыл җирлегендә».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.Й.Әхмәтшин